ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ
2024 елда гражданнарга үзара салым кертү турында Балтач авыл җирлегендә
Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы

2023 елның 27 ноябре № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Балтач авылында гражданнар җыены карар итте:

1.2024 елда, 1 төркем инвалидлардан тыш, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Балтач авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000,00 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (шул исәптән вак таш сатып алу, ташу, салу, су үткәрү торбасын сатып алу, ташу һәм урнаштыру);
- җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү (шул исәптән чишмә будкасын төзекләндерү өчен материаллар сатып алу).

3. Әлеге карарны адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларына урнаштырып халыкка җиткерү:

- ТР Кама Тамагы районы Балтач авылы, Школьная ур., 1 йорт, СДК бинасы;
- ТР Кама Тамагы районы Балтач авылы Школьная ур., 2 йорт, кибет бинасы; шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми сайтында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Кама Тамагы муниципаль районы
Балтач авыл җирлеге башлыгы: Д.И. Мөхәммәдуллин